ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ
**КАРАРЫ**

Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары эшчәнлеге турында Татарстан Республикасы Дәүләт Советы комитетларыннан һәм депутат берләшмәләреннән Татарстан Республикасы Президентына җибәрелә торган мәсьәләләр исемлеге хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советына Татарстан Республикасы Президенты тарафыннан Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары эшчәнлеге турында, шул исәптән Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан куелган мәсьәләләр буенча, хисап бирү хакында Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Регламентының $190^2$ статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары эшчәнлеге турында Татарстан Республикасы Дәүләт Советы комитетларыннан һәм депутат берләшмәләреннән мәсьәләләр исемлеген Татарстан Республикасы Президентына җибәрергә (кушымта итеп бирелә).

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе — Ф.Х. Мөхәммәтшин

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ АППАРАТЫ / АППАРАТ ГОСУДАРСТВЕННОГО СОВЕТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
БЕРКЕТМӘ БҮЛЕГЕ
ПРОТОКОЛЬНЫЙ ОТДЕЛ

Казан шәһәре,
2022 елның 3 феврале
№ 1311-VI ДС

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумының 2022 елның 3 февралендәге 1311-VI ДС номерлы карарына кушымта

**Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары эшчәнлеге турында Татарстан Республикасы Дәүләт Советы комитетларыннан һәм депутат берләшмәләреннән Татарстан Республикасы Президентына җибәрелә торган мәсьәләләр исемлеге**

*Икътисад, бюджет*

1. Татарстан Республикасында автомобиль транспортында пассажирларны йөртү торышы һәм аны үстерү перспективалары турында.

2. Шәһәр яны тимер юл траспортында йөртүне үстерү перспективалары хакында.

3. Территорияләрне комплекслы үстерү өлкәсендә норматив-хокукый база булдыру турында. Татарстан Республикасында территорияләрне комплекслы үстерү буенча пилот проектларны гамәлгә ашыру.

4. Коммуналь хуҗалык оешмаларының инвестицияләр җәлеп итүчәнлеген арттыру механизмнары хакында. Торак-коммуналь хуҗалык челтәрләрен модернизацияләү программаларын эшләү.

5. Татарстан Республикасының пространство үсешен камилләштерү чаралары турында. Агломерацияләрне үстерү проблемалары һәм перспективалары хакында.

6. Шәһәр төзелеше документларында җир асты сулары ятмаларын чагылдыру һәм саклау зоналарын кадастр исәбенә кую чаралары турында.

7. Республикада квалификацияле эшче көчләр кытлыгы проблемасын хәл итү юллары хакында.

8. Хезмәт җитештерүчәнлеген арттыру һәм түбән квалификацияле эш урыннарын бетерү чаралары турында.

9. Республиканың энергетика тармагын модернизацияләү торышы һәм альтернатив энергетиканы үстерү перспективалары хакында.

10. Сәнәгать һәм республика икътисадының башка тармаклары (авыл хуҗалыгы, төзелеш һ.б.) эшенең нәтиҗәлелеген арттыруда IT-компанияләрнең роле турында.

11. «Вайлдберриз», «Озон» иң эре Россия компанияләренең яңа мәйданчыклары ачылуның Татарстан Республикасы икътисадын үстерүгә тәэсир итүе хакында.

12. Салым ташламаларын бирү нәтиҗәлелеге турында.

13. Һөнәр категорияләре буенча бердәм республика вакансияләрнең цифрлы базасын булдыру мөмкинлеге хакында.

*Социаль сәясәт*

14. «Татарстан Республикасының азык-төлек куркынычсызлыгы турында» 2017 елның 13 июлендәге 53-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын Татарстан Республикасы халкының актив һәм сәламәт яшәү рәвешен алып бару өчен кирәкле азык-төлек продуктларын куллануның билгеләнгән рациональ нормаларыннан да ким булмаган күләмнәрдәге ихтыяҗын, шул исәптән алардан физик һәм икътисадый яктан файдалана алу мөмкинлеген, канәгатьләндерү өлешендә үтәү барышы хакында.

15. Россия Федерациясе Президенты В.В. Путинның 2021 елның 21 декабрендәге матбугат конференциясе йомгаклары буенча йөкләмәсен исәпкә алып, өч һәм аннан артык балалы гаиләләргә бирелә торган җир кишәрлекләрен кирәкле инфраструктура (инженерлык, коммуналь) белән тәэмин итү чараларын гамәлгә ашыру турында.

16. Демографик вәзгыятьне яхшыртуга юнәлдерелгән чаралар хакында.

17. Халыкны сыйфатлы эчәргә яраклы су белән тәэмин итүне финанслауны арттыру яисә моның буенча аерым республика программасын булдыру перспективалары турында.

*Сәламәтлек саклау*

18. Коронавирус инфекциясен кичергән гражданнарны дәвалауны дәвам итү (реабилитацияләү) өчен күрелә торган чаралар хакында (әлеге мәсьәләне норматив җайга салу).

19. Татарстан Республикасы районнарында табиблар кытлыгы проблемасын хәл итү өчен күрелә торган чаралар турында.

20. Республиканың зур шәһәрләрендәге яңа микрорайоннар территорияләрендә сәламәтлек саклауның яңа оешмаларын (хастаханәләрен, поликлиникаларын) төзү (ачу) перспективалары, шулай ук Казан шәһәрендә 1 нче балалар күппрофильле хастаханәсенең яңа бинасын төзү хакында.

*Мәгариф, мәдәният*

21. Белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмаларда (шул исәптән муниципаль) тормаган, сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән белем алучыларның Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән ике мәртәбә түләүсез ризык белән туклануын тәэмин итү мәсьәләсен 2022 елда хәл итү перспективалары турында.

22. Яңа торак төзү микрорайоннарында социаль инфраструктураның (балалар белем бирү оешмаларының, мәдәният, сәламәтлек саклау һәм спорт оешмаларының) булмавы мәсьәләсен хәл итү хакында.

23. Шәһәр гомуми белем бирү оешмаларында физик культура белән шөгыльләнү өчен куркынычсыз шартлар тудыру мәсьәләсен хәл итү перспективалары турында. Үз спорт заллары булмаган шәһәр мәктәпләренең саны, капиталь ремонт ясау таләп ителә торган шәһәр мәктәпләренең спорт

залларының (шул исәптән иске төзелеш биналарында урнашканнарының да) саны хакында.

24. Урта һөнәри белем бирү оешмаларының студентлар тулай торакларын капиталь ремонтлау перспективалары турында.

25. Урта һөнәри белем бирү оешмалары студентлары өчен стипендияне арттыру хакында.

26. Туган телләр дәреслекләрен гамәлгә кертү һәм дәреслекләрне федераль исемлеккә кертү эше турында.

27. Татарстан Республикасында мәктәпкәчә оешмаларны һәм гомуми белем бирү оешмаларын педагогик кадрлар белән тәэмин итү чаралары хакында.

28. Белем бирү оешмаларының азык-төлек блоклары, ашханәләре хезмәткәрләренең хезмәт хакын арттыру турында.

29. Дәүләт һәм муниципаль гомуми белем бирү оешмаларында төп гомуми һәм урта гомуми белем бирү уку-укыту программалары буенча белем алучыларны, шулай ук дәүләт һәм муниципаль һөнәри белем бирү оешмаларында белем алучыларны туклану белән тәэмин итүгә түләүләр күләмен арттыру хакында (2021 елда республика бюджетыннан субсидия күләме бер белем алучыга көненә – 8 сум, 2022 елда 8 сум 30 тиен тәшкил итә).

30. Татарстан Республикасы китапханәләрен лимитсыз трафиклы югары тизлектәге интернет белән тәэмин итү турында.

31. Республика бюджетыннан һәм муниципаль бюджетлардан дәүләт китапханәләре һәм муниципаль китапханәләр фондларын систематик туплауны еллык финанслауны арттыру хакында.

32. Уку-укыту процессына психик үсешләрендә тоткарлык булган укучылар өчен урта белем бирүнең яраклаштырылган төп гомуми белем бирү программаларын кертү перспективалары турында.

33. Балаларны тәрбияләү өлкәсендә ата-аналарны агарту проектларын гамәлгә ашыру мөмкинлеге хакында, мәсәлән, ата-аналарның балаларга игътибар күрсәтүе турында социаль реклама эшләү.

*Җәмәгать иминлеге*

34. Татарстан Республикасында мәктәпкәчә оешмаларда һәм гомуми белем бирү оешмаларында иминлекне тәэмин итү буенча Татарстан Республикасында күрелә торган чаралар турында.

35. Балигъ булмаганнар арасында җинаятьчелекне профилактикалау максатларында Татарстан Республикасында үткәрелә торган эш хакында.

36. Финанс пирамидаларын булдыруны профилактикалау максатларында Татарстан Республикасында күрелә торган чаралар турында.

37. Халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән саклау өлкәсендәге Татарстан Республикасы законнарын гамәлгә ашыру барышы хакында.

38. Иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән затларны ресоциальләштерү буенча Татарстан Республикасында үткәрелә торган эш турында.

39. «Интернет» челтәреннән файдаланып җинаятьләр кылуны булдырмауга юнәлдерелгән чаралар хакында.

*Экология*

40. «Хайваннарга карата җаваплы мөнәсәбәт турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2018 елның 27 декабрендәге 498-ФЗ номерлы Федераль законны хуҗасыз хайваннар өчен приютлар булдыру өлешендә үтәү барышы турында.

41. Сыек көнкүреш калдыклары проблемаларын (җыю һәм чыгару) хәл итү юллары хакында.

42. Татарстан Республикасында экология, авыл хуҗалыгы һәм сәнәгать туризмын үстерү чаралары турында.

*Җирле үзидарә мәсьәләләре*

43. «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын инициатив проектларны финанслау өлешендә гамәлгә ашыру перспективалары турында.

44. Инфляция дәрәҗәсен исәпкә алып, Татарстан Республикасында муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәте өчен түләү дәрәҗәсен камилләштерү хакында.

45. Муниципаль кадрларның квалификация дәрәҗәсен арттыруны оештыру турында.